**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 4 июлендәге 2863 номерлы карары**

**Киров районының Күзәмәт урамындагы территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Беренчел документацияне әзерләү үзәге» муниципаль унитар предприятиесе гаризасы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьяларына, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану хакында»гы федераль законның 8 статьясына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 9 апрелендәге 1457 номерлы «Казан шәһәренең Киров районындагы Күзәмәт урамы чикләрендәге территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 февралендәге 522 номерлы карары белән расланган «Юдино» территориясен планлаштыру проекты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә Киров районының Күзәмәт урамындагы территорияне ызанлау проектын расларга;

1.2. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, үзгәртелә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга;

1.3. ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, үзгәртелә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.4. әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

2. Гражданка Р.К.Гариповага **тәкъдим итәм**:

2.1. җир кишәрлегенә дәүләт кадастр исәбе үткәрү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә әлеге карар кушымтасы нигезендә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. җир кишәрлегенә дәүләт кадастр исәбе үткәргәннән соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетына җир кишәрлеген яңадан бүлү турында килешү төзү өчен әлеге карар кушымтасы нигезендә тиешле документларны тапшырырга;

2.3. җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә адреслы номерлар бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен җир кишәрлегенең кадастр номеры турында мәгълүматны тапшырырга;

2.4. җир кишәрлегеннән алга таба файдаланганда:

2.4.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмаларның аларга тоткарлыксыз керүен тәэмин итәргә;

2.4.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 4 июлендәге
2863 номерлы карарына
кушымта

**Киров районының Күзәмәт урамындагы территорияне ызанлау проекты**

Киров районының Күзәмәт урамындагы территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, үзгәртелә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән территорияне ызанлау проекты турындагы нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау сызымы

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, үзгәртелә торган кызыл линияләр чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып торалар һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Карала торган территория Киров районының Кузәмәт урамында урнашкан.

Казан шәһәр округының Генераль планы нигезендә ясала торган җир кишәрлеге ФЗ-201 – шәхси һәм блоклы торак төзелеше зонасында урнашкан (130).

Әлеге территориягә карата Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 февралендәге 522 номерлы карары белән «Юдино» планлаштыру проекты расланды.

Территорияне ызанлау проекты шәхси милектә булган 16:50:281007:11 кадастр номерлы җир кишәрлеген дәүләт милке чикләнмәгән җирләр белән яңача бүлү юлы белән :ЗУ1 җир кишәрлеген ясауны күз алдында тота.

Җир кишәрлеген яңадан бүлү, кишәрлекләрнең бер-берсенә кереп урнашуын булдырмас өчен, җир кишәрлеге чикләрен территориянең расланган ызанлау проектына туры китерү максатыннан башкарыла (таблица).

Җир кишәрлегенең арта торган өлешен тәшкил итә торган территория аз үлчәмле, төзелеш өчен мөстәкыйль әһәмияткә ия түгел, җир кишәрлегендә төзелеш ниятен тормышка ашыру мөмкин түгел.

Шулай ук территорияне ызанлау проектында кызыл линияләрне үзгәртү күздә тотыла. Кызыл линияләрне үзгәртү, гамәлдәге юлны фактта узуны исәпкә алып, фактта җирдән файдалану чикләрендә башкарыла.

| **Кишәр лек номеры** | **Мәйданы, квадрат метрларда** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре:** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | 1064 | 16:50:281007:11 | Шәхси торак төзелеше |

Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгәнчә, алардан җир кишәрлекләре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре ясала торган җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану төре дип танyла. Шулай итеп, ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре турындагы белешмәләр беренчел җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре турындагы белешмәләргә туры килә.

Ясала торган җир кишәрлеге Ж1 территориаль зонасында – шәхси һәм блоклы торак төзелеше зонасында урнашкан.

Ж1 зонасында ясала торган җир кишәрлегенең иң чик минималь һәм максималь үлчәмнәре Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Думасының 2023 елның 14 апрелендәге 7-22 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба –

Кагыйдә) белән билгеләнде. рөхсәт ителгән файдалану төре шәхси торак төзелеше булган ясала торган җир кишәрлегенең максималь үлчәме билгеләнмәгән. Кагыйдәләрнең 24 статьясындагы 7 пунктында ясала торган җир кишәрлеге өчен минималь үлчәмнәр билгеләнмәгән (кулланылмый).


Казан шәһәр округының Генераль планы нигезендә төзелә торган җир кишәрлеге өлешчә табигый-рекреацион комплекс чикләрендә урнашкан. Кагыйдәләр нигезендә табигый-рекреацион комплекс чикләре Р0 территориаль зонасы – махсус табигатьне саклау, рекреацион һәм башка кыйммәтле әһәмияттәге зона составында тәгәлләштерелде.

Ясалган җир кишәрлеге түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- кирәк булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

- эшләп килүче инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, файдаланучы оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.

# II. Территорияне ызанлау сызымы




| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| | ызанлау проектының чиге |
| | ясала торган җир кишәрлеге чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлегенең чиге |
| :ЗУ1 | ясала торган җир кишәрлеге |
| | кызыл линия чиге |
| | гамәлдән чыгарыла торган кызыл линияләр |
| | билгеләнә торган кызыл линияләр |
| ● н5 | ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы ноктасы |
| ● 3 | ызанлау проекты чикләренең характерлы ноктасы |
| ● к1 | билгеләнә торган кызыл линиянең характерлы ноктасы |
| ● 1 | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чикләренең характерлы ноктасы |
| 16:50:281007 | кадастр кварталы |
| 16:50:281007:11 | җир кишәрлегенең кадастр номеры |
| | - беренчел җир кишәрлеге чиге |
| | инженерлык коммуникацияләренең планлаштырыла торган сервитуты чиге |